**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**егерме сигезенче утырыш**
**КАРАРЫ**

14 июнь 2019 ел **№ 179** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2017 елның 22 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, бер генә башкарма орган буларак, коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы 103 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында».

2017 елның 29 июлендәге «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217 номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2017 елның 22 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, бер генә башкарма орган буларак, коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында»гы 103 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, бер генә башкарма орган буларак, коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәдә:

– 1 пункттагы «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы И.Ф. Зарипов